**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 18 май № 354

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибен раслау турында» 2013 ел, 19 июнь, 416 нчы карары белән расланган Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибен раслау турында» 2013 ел, 19 июнь, 416 нчы карары белән расланган Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибенә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 12 апрель, 237 нче, 2015 ел, 15 апрель, 255 нче каралары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7.5 пунктта:

«в» һәм «е» пунктчаларында «50» саннарын «70» саннарына алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле яңа «и» һәм «к» пунктчалары белән тулыландырырга:

«и) эшли башлаучы эшмәкәрлек субъектларына – авыл хуҗалыгы кооперативларына җиһазларның финанс арендасы (лизинг) шартнамәсен төзегәндә беренче кертемне (авансны) түләүгә максатчан чыгымнарны өлешле финанслау шартларында финанс арендасы (лизинг) шартнамәсе суммасының 50 проценты күләмендә, әмма бер алучыга 1,0 млн.сумнан артык түгел;

к) эшләүче эшмәкәрлек субъектларына – авыл хуҗалыгы кооперативларына финанс арендасы (лизинг) шартнамәсе буенча аванс түләвенә гамәлдә тотылган

чыгымнарның финанс арендасы (лизинг) шартнамәсе суммасының 50 проценты күләмендә, әмма бер алучыга 3,0 млн.сумнан артык түгел.».

2. Әлеге карарның көче 2015 елның 23 апреленнән килеп туган хокук мөнәсәбәтләренә тарала дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\354.doc